**Совет Большеачасырского сельского поселения Зеленодольского муниципального района Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл жирлеге Советы**

РЕШЕНИЕ

КАРАР

30 сентябрь 2020 ел

№9

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2018 елның 25 апрелендәге 145 номерлы «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы "Олы Ачасыр авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләүне җайга салу максатларында һәм «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 2020 елның 5 августындагы 655 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып, Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2018 елның 25 апрелендәге 145 номерлы «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы "Олы Ачасыр авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләме бюджет өлкәсенең аерым оешмасы структур бүлекчәсе җитәкчесе сәркатибенең, бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең Олы Ачасыр авыл җирлеге башкарма комитетында вазыйфаи окладының күләме 11 498 сум тәшкил итә;".

2. Әлеге карар 2020 елның 1 октябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы),

Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Олы Ачасыр авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Олы Ачасыр авыл жирлеге башлыгы, Совет рәисе** **М.Г. Гатиятуллин**